МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

12.07.2018 г.Казань № 550

ТР Юстиция министрлыгында 2018 елның 30 июлендә 4807 номеры белән теркәлде

Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү хакында

Дәүләт хезмәтләрен күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү һәм
социаль яклау министрлыгының
12.07. 2018 № 550 боерыгы белән
расланды

Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләр

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы хезмәт базарында эшсез гражданнарның социаль адаптациясе буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 15 сентябрендәге 649 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 № 317, 28.09.2016 № 549 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы хезмәт базарында эшсез гражданнарның социаль адаптациясе буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

1 бүлектә:

1.6 пунктка түбәндәге эчтәлекле яңа 1.6.1 пунктча өстәргә: «дәүләт хезмәте күрсәтү турында гражданнардан гаризалар кабул итү графигы халыкның мәшгульлек үзәгенең эш графигы белән туры килә»;

1.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.8. Дәүләт хезмәте түбәндәгеләргә нигезләнеп күрсәтелә:

«Россия Федерациясендә халык мәшгульлеге турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы Россия Федерациясе Законы («Ведомости Съезда народных депутатов РСФСР и Верховного Совета РСФСР», 1991, № 18, 565 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);[10]

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 1995, № 48, 4563 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре турында һәм мәгълүмат яклау турында» 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2006, № 31, 3448 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2006, № 31, 3451 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2010, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);[11]

«Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2011, № 15, 2036 ст., кертелгән

[10] Алга таба – Халык мәшгульлеге турында закон
[11] Алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон

үзгәрешләрен исәпкә алып);[12]

«Дәүләти һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2013, № 14, 1652 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);[13]

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2002, № 1, 3 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы Указы (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2012, № 19, 2338 ст.);[14]

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт вазыйфаларын үтәүнең административ регламентларын һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау турында» 2011 елның 16 маендагы 373 номерлы карары (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2011, № 22, 3169 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Халыкның мәшгульлегенә булышлык күрсәтү һәм эшсез гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү буенча чараларны финанслау тәртибе турында нигезләмә раслау турында» 2005 елның 29 июлендәге 485 номерлы боерыгы («Российская газета», 2005, 30 сентябрь);

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Халыкның (физик затларның һәм эш бирүчеләрнең) мәшгульлеге өлкәсендә дәүләт хезмәтләре алучыларның регистрларын алып бару тәртибе турында, аларга белешмәләр бирү тәртибен, срокларын һәм формасын да кертеп» 2010 елның 8 ноябрендәге 972н номерлы боерыгы («Российская газета», 2011, 2 февраль);

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Хезмәт базарында эшсез гражданнарның социаль адаптациясе буенча дәүләт хезмәтенең федераль дәүләт стандартын раслау турында» 2013 елның 9 гыйнварындагы 3н номерлы боерыгы («Российская газета», 2013, 22 май);[15]

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Халык мәшгульлегенә булышлык күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре алучының шәхси эш бланклары формаларын раслау турында» 2015 елның 26 февралендәге 125н номерлы боерыгы (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2015, 6 апрель);[16]

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Медик-социаль экспертиза буенча дәүләт учреждениеләреннән бирелә торган инвалидны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең хосусый программасын, инвалид баланы тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең хосусый программасын эшләү һәм гамәлгә ашыру тәртибен һәм аларның формаларын раслау турында» 2017 елның 13 июнендәге 486н номерлы боерыгы (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2018, 4 июнь);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы

---

[12] Алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон
[13] Алга таба – 44-ФЗ номерлы Федераль закон
[14] Алга таба – 601 номерлы Указ
[15] Алга таба – 3н номерлы Федераль стандарт
[16] Алга таба – 125н номерлы боерык

Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре» 2007 елның 15 августындагы 388 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2007, № 33, 1178 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарында дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып).»;[17]

2.4 пунктның 2 бүлегендә:

таблицаның 2 графасында «30 календарь көненнән артык булырга тиеш түгел» сүзләрен «15 календарь көненнән артык булырга тиеш түгел» сүзләренә алмаштырырга;

таблицаның 3 графасында «59-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен «210-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләренә алмаштырырга;

5 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затның (хезмәткәрнең) яисә дәүләт граждан хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) мөрәҗәгать итүче тарафыннан судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү

5.1. Дәүләт хезмәтен алучылар судка кадәр тәртиптә дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы ХМҮ белгечләренең гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата ХМҮ җитәкчесенә дәгъва белдерү хокукына ия.

ХМҮ җитәкчесе тарафыннан кабул итеп алынган карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр Министрлыкка министрның тикшереп торучы урынбасары яисә министр исеменә тапшырыла.

Министр урынбасары (министр) кабул иткән карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмауга) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына шикаятьләр белдерелергә мөмкин.

Министр урынбасары (министр) кабул иткән карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмауга) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына шикаятьләр белдерелергә мөмкин.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамәсен теркәүгә алу чоры бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган документлар таләп ителгәндә;

---

[17] Алга таба – ТР МК 880 номерлы карары белән расланган Тәртип

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган гаризаны һәм документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм бүтән норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәтен күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка төрле норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче ХМҮнең, дәүләт хезмәте күрсәтүче ХМҮ вазыйфаи затының (белгеченең) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда үзләре тарафыннан җибәрелгән басма хаталарны, ялгышларны төзәтүдән баш тарткан очракта яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда.

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса.

5.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче ХМҮнең, дәүләт хезмәте күрсәтүче ХМҮ вазыйфаи затының (белгеченең) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять язмача формада кәгазьдә яисә электрон формада тапшырыла.

Дәүләт хезмәтен алучылар тарафыннан шикаять почта белән, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайтыннан (http//mtsz.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә кабул итеп алынырга мөмкин.

5.4. ХМҮ, яисә югары торучы органга (Министрлыкка) килгән шикаять аны теркәүгә алганнан соң унбиш эш көне эчендә, ә дәүләт хезмәте күрсәтүче органның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән басма хаталарын һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә каралырга тиеш.

5.5. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) дәүләт хезмәте күрсәтүче, карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган ХМҮ, ХМҮ вазыйфаи затының (белгеченең) аталышы;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) яшәгән урыны турында белешмәләр яисә аталышы, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта ) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәтен күрсәтүче ХМҮнең, ХМҮнең дәүләт хезмәтен күрсәтүче вазыйфаи затының (белгеченең) шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

4) мөрәҗәгать итүченең хезмәт күрсәтүче ХМҮнең, дәүләт хезмәте күрсәтүче ХМҮ вазыйфаи затының (белгеченең) карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләр.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча үз исеменә шикаять тапшырылган вазыйфаи зат түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән язу һәм басма хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Карарны кабул иткән көннән соң бер көн узганчы мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә аның ихтыяры буенча электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.7. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.»;

Административ регламентка 1 нче кушымтада түбәндәге эчтәлекле позицияләрне:

| | | |
|---|---|---|
| «Зәй ш. халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ» | (85558) 7-15-43 | 423520, Зәй ш., Нефтьчеләр пр., 39, Czn.Zainsk@tatar.ru» |
| «Вахитов районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (843) 277-51-59 | 420059, Казан ш., Павлюхин ур., 102, Czn.Vah@tatar.ru |
| «Актаныш районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (85552) 3-09-83 | 423740, Актаныш ав., Ленин пр., 8 Czn.Aktanysh@tatar.ru |
| «Югары Ослан районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84379) 2-18-99 | 422570, Югары Ослан ав., Медгородок ур., 1 Czn.V-uslon@tatar.ru |
| «Чүпрәле районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84375) 2-25-87 | 422470, Иске Чүпрәле ав., Мәктәп ур., 16 Czn.Drozhzhanoe@tatar.ru |
| Кама Тамагы районы буенча Тәтеш районы халыкның мәшгульлек үзәге филиалы | (84377) 2-14-67 | 422820, Кама Тамагы ш.т.п., Карл Маркс ур., 2 Filial.K-uste@tatar.ru |
| «Лаеш районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84378) 2-48-12 | 422610, Лаеш штп., Первомайская ур., 16 Eaish.Czn@tatar.ru |
| «Мамадыш районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (85563) 3-35-57 | 422190, Мамадыш ш., Карл Маркс ур., 14 Czn.Mamadysh@tatar.ru |
| «Минзәлә районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (85555) 3-23-80 | 423700, Минзәлә., Ленин ур., 78 Czn.Menzelinsk@tatar.ru |
| «Яңа Чишмә районы халыкның | (84348) | 423190, Яңа Чишмә ав., Совет ур., |

| | | |
|---|---|---|
| мәшгульлек үзәге» ДКУ | 2-30-42 | 80 Czn.Novoshesh@tatar.ru |
| «Саба районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84362) 2-44-11 | 422060, Байлар Сабасы штп., Тукай ур., 87 SZN.Saby@tatar.ru |
| «Ютазы районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (85593) 2-98-00 | 423950, Урыссу штп., Пушкин ур., д. 38 Czn.Yutazy@tatar.ru« |

түбәндәге эчтәлекле позицияләр белән алмаштырырга:

| | | |
|---|---|---|
| «Зәй ш. халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ» | (85558) 7-15-43 | 423520, Зәй ш., Нефтьчеләр пр., 37б, Czn.Zainsk@tatar.ru» |
| «Вахитов районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (843) 277-51-59 | 420049, Казан ш., Качалов ур., 77, Czn.Vah@tatar.ru |
| «Актаныш районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (8-85552) 3-09-83 | 423740, Актаныш районы, Актаныш ав., Ленин пр., 61 Czn.Aktanysh@tatar.ru |
| «Югары Ослан районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (8-84379) 2-24-28 | 422570, Югары Ослан районы, Югары Ослан ав., Медгородок ур., 21а Czn.V-uslon@tatar.ru |
| «Чүпрәле районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (8-84375) 2-24-51 | 422470, Иске Чүпрәле ав., Үзәк ур., 15 й.Czn.Drozhzhanoe@tatar.ru |
| Кама Тамагы районы буенча Тәтеш районы халыкның мәшгульлек үзәге филиалы | (8-84377) 2-14-67 | 422820, Кама Тамагы районы, Кама Тамагы штп., К. Маркс ур., 2а Filial.K-uste@tatar.ru |
| «Лаеш районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (8-84378) 2-44-54 | 422610, Лаеш ш., Чернышевский ур., 23 Laish.Czn@tatar.ru |
| «Мамадыш районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (8-85563) 3-35-57 | 422190, Мамадыш ш., Муса Җәлил ур., 12 Czn.Mamadysh@tatar.ru |
| «Минзәлә районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (8-85555) 3-23-80 | 423700, Минзәлә., Ленин ур., 80 Czn.Menzelinsk@tatar.ru |
| «Яңа Чишмә районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (8-84348) 2-23-43 | 423190, Яңа Чишмә районы, Яңа Чишмә ав., Ленин ур., 93 Czn.Novoshesh@tatar.ru |
| «Саба районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (8-84362) 2-28-15 | 422060, Саба районы, Байлар Сабасы ш.т.п., З.Йосыпов ур., 7 SZN.Saby@tatar.ru |
| «Ютазы районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (8-85593) 2-60-18 | 423950, Урыссу ш.т.п., Пушкин ур., 105/1 й., Czn.Yutazy@tatar.ru«; |

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасында эшсез гражданнарга психологик ярдәм курсәтү дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 28 сентябрендәге 674 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 № 317 боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасында эшсез гражданнарга психологик ярдәм курсәтү дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

1 бүлектә:

1.6 пунктка түбәндәге эчтәлекле яңа 1.6.1 пунктча өстәргә: «дәүләт хезмәте күрсәтү турында гражданнардан гаризалар кабул итү графигы халыкның мәшгульлек үзәгенең эш графигы белән туры килә»;

1.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.8. Дәүләт хезмәте түбәндәгеләргә нигезләнеп күрсәтелә:

«Россия Федерациясендә халык мәшгульлеге турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы Россия Федерациясе Законы («Ведомости Съезда народных депутатов РСФСР и Верховного Совета РСФСР», 1991, № 18, 565 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып)[10];

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 1995, № 48, 4563 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре турында һәм мәгълүмат яклау турында» 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2006, № 31, 3448 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2006, № 31, 3451 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2010, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып)[11];

«Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2011, № 15, 2036 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып) [12];

«Дәүләти һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2013, № 14, 1652 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2002, № 1, 3 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып) [13];

Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы Указы (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2012, № 19, 2338 ст.) [14];

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт вазыйфаларын үтәүнең административ регламентларын һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау турында» 2011 елның 16 маендагы 373 номерлы карары (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2011, № 22, 3169 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

---

[10] Алга таба – Халык мәшгульлеге турында закон
[11] Алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон
[12] Алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон
[13] Алга таба – 44-ФЗ номерлы Федераль закон
[14] Алга таба – 601 номерлы Указ

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Халыкның мәшгульлегенә булышлык күрсәтү һәм эшсез гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү буенча чараларны финанслау тәртибе турында нигезләмә раслау турында» 2005 елның 29 июлендәге 485 номерлы боерыгы («Российская газета», 2005, 30 сентябрь);

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Халыкның (физик затларның һәм эш бирүчеләрнең) мәшгульлеге өлкәсендә дәүләт хезмәтләре алучыларның регистрларын алып бару тәртибе турында, аларга белешмәләр бирү тәртибен, срокларын һәм формасын да кертеп» 2010 елның 8 ноябрендәге 972н номерлы боерыгы («Российская газета», 2011, 2 февраль);

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль үсеш министрлыгының «Эшсез гражданнарга психологик ярдәм күрсәтү буенча дәүләт хезмәтенең федераль дәүләт стандартын раслау турында» 2013 елның 9 гыйнварындагы 4н номерлы боерыгы («Российская газета», 2013, 13 июнь) [15];

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Халык мәшгульлегенә булышлык күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре алучының шәхси эш бланклары формаларын раслау турында» 2015 елның 26 февралендәге 125н номерлы боерыгы (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2015, 6 апрель)[16];

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Медик-социаль экспертиза буенча дәүләт учреждениеләреннән бирелә торган инвалидны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең хосусый программасын, инвалид баланы тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең хосусый программасын эшләү һәм гамәлгә ашыру тәртибен һәм аларның формаларын раслау турында» 2017 елның 13 июнендәге 486н номерлы боерыгы (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2018, 4 июнь);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре» 2007 елның 15 августындагы 388 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2007, № 33, 1178 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарында дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып).»;

2.4 пунктның 2 бүлегендә:

---

[15] Алга таба ⁻ 4н номерлы Федераль стандарт
[16] Алга таба – 125н номерлы боерык
[17] Алга таба – ТР МК 880 номерлы карары белән расланган Тәртип

таблицада 1 графада «дәүләт хезмәтләрен» сүзләреннән соң «туктатып тору мөмкинлеге Россия Федерациясе законнарында каралган очракта дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору срогы»;

таблицаның 2 графасында түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә: «Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору Россия Федерациясе законнарында каралмаган»;

таблицаның 3 графасында «№ 726 Административ регламентның 32 п.» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.8 пунктның 2 бүлегендә:

таблицаның 2 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре каралмаган»;

таблицаның 3 графасында «№ 726 Административ регламентның 32 п.» сүзләрен төшереп калдырырга;

5 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затның (хезмәткәрнең) яисә дәүләт граждан хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) мөрәҗәгать итүче тарафыннан судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү

5.1. Дәүләт хезмәтен алучылар судка кадәр тәртиптә дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы ХМҮ белгечләренең гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата ХМҮ җитәкчесенә дәгъва белдерү хокукына ия.

ХМҮ җитәкчесе тарафыннан кабул итеп алынган карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр Министрлыкка министрның тикшереп торучы урынбасары яисә министр исеменә тапшырыла.

Министр урынбасары (министр) кабул иткән карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмауга) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына шикаятьләр белдерелергә мөмкин.

Министр урынбасары (министр) кабул иткән карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмауга) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына шикаятьләр белдерелергә мөмкин.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамәсен теркәүгә алу чоры бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган документлар таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган гаризаны һәм документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм бүтән норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәтен күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка төрле норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче ХМҮнең, дәүләт хезмәте күрсәтүче ХМҮ вазыйфаи затының (белгеченең) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда үзләре тарафыннан җибәрелгән басма хаталарны, ялгышларны төзәтүдән баш тарткан очракта яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда.

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса.

5.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче ХМҮнең, дәүләт хезмәте күрсәтүче ХМҮ вазыйфаи затының (белгеченең) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять язмача формада кәгазьдә яисә электрон формада тапшырыла.

Дәүләт хезмәтен алучылар тарафыннан шикаять почта белән, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайтыннан (http//mtsz.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә кабул итеп алынырга мөмкин.

5.4. ХМҮ, яисә югары торучы органга (Министрлыкка) килгән шикаять аны теркәүгә алганнан соң унбиш эш көне эчендә, ә дәүләт хезмәте күрсәтүче органның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән басма хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә каралырга тиеш.

5.5. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) дәүләт хезмәте күрсәтүче, карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган ХМҮ, ХМҮ вазыйфаи затының (белгеченең) аталышы;

